| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Александровское сельское поселение Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге** |

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>«25» ноября 2024г | **КАРАР**<br>№ 114 |

«2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге бюджеты турында " Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы Карары проектын кабул итү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче маддәсыннан, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

1. «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровкаавыл җирлеге бюджеты турында»Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы Карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән җөмләләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. "2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге бюджеты турында" Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы Карары проектына килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

-Вафин Ирек Фатих улы төркем җитәкчесе;
- Еремин Александр Николай улы-төркем әгъзасы;
- Халиуллин Марат Гаяз улы -төркем әгъзасы;
- Миннебаев Магсум Талгат улы -төркем әгъзасы;
- Суербаев Гумер Амир улы - төркем әгъзасы;

4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә эшче төркемгә Ф. И. О., туган елы, авторның адресы, ТР, Александровка авылы, Мэктэп урамы, 7йорт адресы буенча җибәрелә.

5. «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы карары проекты буенча 2024елның 6 декабренә 14.00 сәгатьтә авыл җирлеге Советы утырышлар залында ачык тыңлаулар билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы каравына 2024 елның 11 декабренә кадәр кертергә.
7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе
Александровка авыл җирлеге
Сарман муниципаль районы
Татарстан Республикасы И.Ф.Вафин